СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь 2022 №51

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Карадуган авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җәмәгать тыңлауларын (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 11.06.20021 ел, № 191-ФЗ Федераль закон нигезендә, «халык алдында тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» гы 15.04.2002 ел, №02-08-01-2022 протесты һәм Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Уставы нигезендә, Карадуган авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1.Җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 4 пунктындагы икенче абзацында «язма рәвештә» сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: «яисә электрон документ рәвешендә җәмәгать тыңлауларын яисә иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына»;

1.2. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 5 пунктында «язма» сүзеннән соң «яки электрон документ рәвешендә» сүзтезмәсен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 7 статьясының 6 пунктында «язма» сүзеннән соң «яки электрон документ формасында» сүзтезмәсен өстәргә;

1.4. Нигезләмәнең 8 статьясының 2 пунктында «язма рәвештә» сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзтезмә өстәргә: «яисә электрон документ рәвешендә иҗтимагый фикер алышуларны яисә җәмәгать тыңлауларын оештыручы адресына»;

1.5. Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында «язмача» сүзеннән соң «яки электрон формада» сүзтезмәсен өстәргә .

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә .

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш. В. Низамиев